Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17.09.2015 ел № 4

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил поселогы» МБ Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына конкурс турында»

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 26.3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 27 маендагы 136-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законны кабул итүгә бәйле рәвештә, Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе - җирле администрация башлыгы вазыйфасына конкурс комиссияләрен формалаштыру тәртибе үзгәртелде.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 37 статьясы, (Татарстан Республикасында җирле үзидарәдә» 28.07.2004 ел, №45 ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы» поселогы «муниципаль берәмлеге Уставының 51 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итәргә.

3. 2015 елның 21 сентябреннән 2015 елның 12 октябренә кадәр Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләү, дәгъвачылардан документлар 2015 елның 21 сентябреннән 2015 елның 12 октябренә кадәр Җәлил ш. т.п. адресы буенча кабул итәргә. Әхмәдиев ур., 26.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы
Советы Рәисе М.Ш.Каюмов